КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 641

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бер берәмлек саклана торган архив документларын карап тоту чыгымнары нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына дәүләт милкенә караган архив документларын саклауга, туплауга, исәпкә алуга һәм алардан файдалануга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенция күләмен исәпләү өчен бер берәмлек саклана торган архив документларын карап тоту чыгымнары нормативын 15,77 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « 2024 – 2026 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында» 2023 ел, 3 август, 939 нчы карары 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин